**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 6 июль № 498

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга түбәндәге эчтәлекле яңа $1^1$ нче пункт өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен куллану буенча аңлатмалар бирү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\498.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 498 нче карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – Тәртип) даими Россия Федерациясе территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга һәм өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган качакларга (алга таба – социаль хезмәтләрдән файдаланучылар) Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләрен билгели.

1.2. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү үз эченә социаль хезмәтләрдән файдаланучылар гадәти булган уңай мохиттә – яшәү урынында калган шартларда аларның тереклек эшчәнлеге шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы (алга таба – индивидуаль программа) нигезендә социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга социаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген ала.

1.3. Социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләрнең түбәндәге төрләре күрсәтелә:

көнкүрештә социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның тереклек эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән социаль-көнкүреш төре;

тәрбияләп торуны оештыру, савыктыру чараларын үткәрүдә булышу, сәламәтлекләре торышындагы тайпылышларны ачыклау өчен системалы рәвештә күзәтеп тору юлы белән социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның сәламәтлеген саклауга һәм тиешле хәлдә тотуга юнәлдерелгән социаль-медицина төре;

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның документларын рәсмиләштерүдә һәм торгызуда ярдәм күрсәтүгә, юридик хезмәтләр күрсәтүдән файдалануда ярдәм итүгә юнәлдерелгән социаль-хокукый төре;

өйдә тәрбияләнә торган инвалид балаларның ата-аналарына яки законлы вәкилләренә мондый балаларны аларның шәхесен үстерүгә юнәлдерелгән, үз-

үзләренә хезмәт күрсәтү, аралашу һәм тикшерүдә тоту күнекмәләренә өйрәтү буенча ярдәм оештыруга йөз тоткан социаль-педагогик төре.

1.4. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләрдән файдаланганда:

1.4.1. Социаль хезмәтләрдән файдаланучылар түбәндәгеләргә хокуклы:

ихтирамлы һәм кешелекле мөнәсәбәткә;

үз хокуклары һәм бурычлары турында, социаль хезмәтләрнең төрләре, аларны күрсәтү вакытлары, тәртибе һәм шартлары хакында, әлеге хезмәтләргә тарифлар һәм аларның кыйммәте турында, әлеге хезмәтләрдән түләүсез файдалану мөмкинлеге, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр хакында ачык формада түләүсез мәгълүмат алуга;

социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчене яки тәэмин итүчеләрне сайлауга;

өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүдән баш тартуга. Баш тарту язма рәвештә рәсмиләштерелә һәм индивидуаль программага кертелә;

Россия Федерациясе законнары нигезендә үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга;

индивидуаль программаларны төзүдә катнашуга;

өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәткәндә мәгълүм булган шәхси характердагы мәгълүматның конфиденциальлегенә.

1.4.2. Социаль хезмәтләрдән файдаланучылар түбәндәгеләргә бурычлы:

Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматлар һәм документлар тапшырырга;

өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә ихтыяҗның сәбәбе булган һәм җан башына уртача керем күләменә йогынты ясый торган хәлләр үзгәрү турында, әлеге үзгәрешләр барлыкка килгән көннән соң, биш көн эчендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә язма рәвештә хәбәр итәргә;

социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче белән төзегән шартнамә шартларын үтәргә, шул исәптән хезмәтләр түләүле яки өлешчә түләүле нигездә күрсәтелгәндә, социаль хезмәтләр күрсәткән өчен үз вакытында һәм тулы күләмдә түләргә.

## II. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемнәре һәм стандартлары

2.1. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү стандартлары нигезендә күрсәтелә.

социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемнәре һәм стандартлары әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтада китерелә.

## III. Социаль хезмәтләрне түләүсез яисә түләүле яки өлешчә түләүле нигездә күрсәтү кагыйдәләре

3.1. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан түләүсез, түләүле яки өлешчә түләүле нигездә күрсәтелә.

3.2. Социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче һәм социаль хезмәтләрдән файдаланучы (законлы вәкиле) арасындагы өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) нигезендә башкарыла.

Шартнамәнең җитди шартлары булып индивидуаль программада билгеләнгән нигезләмәләр, шулай ук социаль хезмәтләр түләүле яки өлешчә түләүле нигездә күрсәтелсә, аларның кыйммәте тора.

3.3. Түләүсез, түләүле яки өлешчә түләүле нигездә өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан законнар таләпләренә ярашлы рәвештә, социаль хезмәтләрдән файдаланучы (законлы вәкиле) тапшыра торган һәм әлеге Тәртипнең 5.1 нче пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә, социаль хезмәтләрдән файдаланучының җан башына уртача керемен, социаль хезмәтләрне түләүсез күрсәтү өчен җан башына уртача керемнең Татарстан Республикасында билгеләнгән иң чик күләмен һәм социаль хезмәтләрдән файдаланучының категориясен исәпкә алып кабул ителә.

3.4. Шартнамә төзегәндә социаль хезмәтләрдән файдаланучының җан башына уртача керемен социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Түләүсез социаль хезмәтләр күрсәтү өчен җан башына уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 ел, 18 октябрь, 1075 нче карары нигезендә, социаль хезмәтләрдән файдаланучы тапшыра торган гаилә составы, гаилә әгъзаларының яки ялгыз яшәүче гражданның керемнәре булу (булмавы) һәм аларның (аның) милек хокукында булган мөлкәте турындагы документлар (мәгълүматлар) буенча хисаплап чыгара.

3.5. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр түбәндәгеләргә түләүсез күрсәтелә:

3.5.1. Гаиләләрендә чит кешеләр тәрбиясенә даими мохтаҗ инвалид бала яки инвалид балалар булган гражданнарга;

3.5.2. «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 ел, 28 декабрь, ФЗ-442 нче Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 31 статьясындагы 1 нче пунктта күрсәтелгән социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга;

3.5.3. Ялгыз һәм ялгыз яшәүче гражданнарга*, түбәндәгеләр арасыннан гаилә әгъзалары гамәлдәге законнар нигезендә тәрбияләргә тиеш булып та объектив сәбәпләр буенча ярдәм һәм тәрбия белән тәэмин итә алмый торган гаиләләрдә яшәүче

* Әлеге Тәртипне тормышка ашыру максатларында:

үзләренең эшкә яраксыз, ярдәмгә мохтаҗ булган туганнарын карарга тиешле затларга эшкә яраклы балигъ булган балалар, оныклар, эшкә яраклы ата-аналар, ир белән хатын керә;

ялгыз яшәүче социаль хезмәт күрсәтүдән файдаланучыларга Татарстан Республикасыннан читтә йә якын туганнарына һәр көн саен ярдәм итеп һәм аларны карап торырга мөмкинлек бирә торган әледән-әле йөреп торучы гомуми

гражданнарга:

Бөек Ватан сугышы инвалидларына;

Бөек Ватан сугышында катнашучыларга;

хәрби хәрәкәтләр инвалидларына;

Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары төзегән концлагерьлар, гетто һәм башка мәҗбүри тоту урыннарының элекке балигъ булмаган тоткыннарына;

Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга;

3.5.4. Хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көнгә җан башына уртача керемнәре социаль хезмәтләрне түләүсез күрсәтү өчен җан башына уртача керемнең Татарстан Республикасында билгеләнгән иң чик күләменнән түбәнрәк яки иң чик күләмгә тигез булган гражданнарга.

3.6. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 ноябрь, 927 нче карары нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан хисаплап чыгарыла.

3.7. Социаль хезмәт күрсәтү процессында түләү күләмен яңадан исәпләү социаль хезмәтләрне түләүсез күрсәтү өчен җан башына уртача керемнең Татарстан Республикасында билгеләнгән иң чик күләме үзгәргәндә, һәм (яки) социаль хезмәтләргә тарифлар һәм (яки) социаль хезмәтләрдән файдаланучының җан башына уртача кереме үзгәргәндә, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.8. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр түләүле нигездә күрсәтелә, социаль хезмәт күрсәтү процессында социаль хезмәтләрдән файдаланучының җан башына уртача кереме социаль хезмәтләрне түләүсез күрсәтү өчен җан башына уртача керемнең Татарстан Республикасында билгеләнгән иң чик күләменнән арткан очракта.

## IV. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр эшчәнлегенә карата таләпләр

4.1. Социаль хезмәтләр өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә күрсәтелгәндә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче түбәндәгеләрне эшләргә тиеш:

кеше һәм граждан хокукларын якларга;

социаль хезмәтләрдән файдаланучылар шәхесе кагылгысызлыгын һәм иминлеген тәэмин итәргә;

---

файдаланудагы шәһәр яки шәһәр яны элемтәсе булмаган Татарстан Республикасының башка торак пунктында яшәүче туганнары ярдәменә мохтаҗ эшкә яраксыз туганнарын тәрбияләп торырга тиешле затлары булган өлкән яшьтәге гражданнар һәм (яки) инвалидлар керә.

социаль хезмәтләрдән файдаланучылар турындагы мәгълүматтан Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән шәхси мәгълүматларны яклау хакындагы таләпләргә туры китереп файдаланырга;

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга социаль хезмәтләрне индивидуаль программалар һәм шартнамәләр шартлары нигезендә күрсәтергә;

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга яки аларның законлы вәкилләренә хокуклары һәм бурычлары турында, социаль хезмәтләрнең төрләре, аларны күрсәтү вакытлары, тәртибе һәм шартлары хакында, әлеге хезмәтләргә тарифлар турында һәм социаль хезмәтләрдән файдаланучылар өчен аларның кыйммәте яисә әлеге хезмәтләрдән түләүсез файдалану мөмкинлеге хакында ачык формада түләүсез мәгълүмат бирергә;

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны (аларның законлы вәкилләрен) социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең үз эшчәнлеген гамәлгә ашыруы өчен нигез булып торучы хокук билгели торган документлар белән таныштыруны тәэмин итәргә;

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның шәхси һәм кыйммәтле әйберләре саклануын тәэмин итәргә;

Федераль законның 22 статьясы нигезендә социаль ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашырырга;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр реестрын һәм социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар регистрын төзү һәм алып бару турында» 2014 ел, 23 декабрь, 1012 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар регистрын формалаштыру өчен мәгълүмат бирергә;

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә хокукларын гамәлгә ашыру белән бәйле башка вазыйфалар үтәргә.

4.2. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр түбәндәгеләргә хокуклы:

социаль хезмәтләрдән файдаланучы шартнамә шартларын бозган очракта, аңа социаль хезмәт күрсәтүдән баш тартырга;

гражданнарга аларның язмача яки электрон рәвештә белдерелгән теләге буенча өстәмә түләүле социаль хезмәтләр күрсәтергә.

4.3. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәткәндә түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләргә, шул исәптән медицина куллану өчен дару препаратларыннан файдаланганда;

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга карата физик яки психологик көч кулланырга, аларны рәнҗетүгә, алар белән дорфа кылануга юл куярга.

4.4. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр, индивидуаль программада каралган шартларны үтәп, өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итә, һәм аларга түбәндәге социаль хезмәтләрне күрсәтү кирә:

социаль хезмәтләрдән файдаланучының яшәү урыны буенча;

шимбә һәм якшәмбедән тыш, эш һәм бәйрәм көннәрендә, көндезге вакытта 8.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

социаль хезмәтләрдән файдаланучының көнкүреш һәм башка йорт җиһазларыннан һәм инвентареннән, социаль хезмәтләрдән файдаланучылар акчасы исәбеннән сатып алына торган материалларны һәм хезмәтләрне кулланып.

4.5. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга индивидуаль программалар һәм шартнамә нигезендә күрсәтелә.

Шартнамә, әлеге Тәртипнең 5.1 нче пунктындагы 5.1.2 – 5.1.6 пунктчаларда күрсәтелгән документлар тапшырылганда, индивидуаль программаны керткән көннән соң бер тәүлек эчендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан төзелә.

4.6. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүне туктату өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

социаль хезмәтләрдән файдаланучының өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүдән баш тарту турында язмача гаризасы;

индивидуаль программа нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү вакыты тәмамлану һәм (яки) шартнамәнең гамәлдә булу вакыты чыгу;

социаль хезмәтләрдән файдаланучының (законлы вәкиленең) шартнамәдә каралган шартларны бозуы;

социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчене ябу (эшчәнлеген туктату);

социаль хезмәтләрдән файдаланучының үлеме;

социаль хезмәтләрдән файдаланучыны хәбәрсез югалган яки үлгән дип тану турында суд карары;

социаль хезмәтләрдән файдаланучыны ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җәзага тартып хөкем итү.

4.7. Социаль хезмәтләр күрсәтүгә теркәлүне, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүне туктатуны социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче боерык белән рәсмиләштерә.

4.8. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче законнарда күздә тотылган тәртиптә һәм шартларда социаль хезмәтләр күрсәтү буенча документлар алып баруны гамәлгә ашыра, шул исәптән мәгълүмат системаларын кулланып.

Һәр социаль хезмәтләрдән файдаланучыга аны социаль хезмәт күрсәтүгә кабул иткәндә шәхси эш формалаштырыла, ул социаль хезмәтләр күрсәтү процессында алып барыла һәм, аларны күрсәтү тәмамланганнан соң, Россия Федерациясе законнары нигезендә архивлаштырыла.

4.9. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең социаль хезмәтләр күрсәтүче хезмәткәрләренең эш көне башлану, тәмамлану вакыты һәм төшке аш вакыты социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән регламентлаштырыла.

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче хезмәткәрләренең эш режимы, социаль хезмәтләрдән файдаланучыга өйдә хезмәт күрсәтү графигы (хезмәт күрсәтелә торган атна көне, тәүлек вакыты) турында тулы мәгълүмат шартнамәдә күрсәтелә.

4.10. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга күрсәтә торган социаль хезмәтләр сыйфатын билгели торган төп күрсәткечләр булып түбәндәгеләр тора:

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның социаль хезмәтләрдән канәгатьлелеген тасвирлый торган күрсәткечләр, нигезләнгән шикаятьләр булмау, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче эше турында уңай бәяләмәләр саны;

алар нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче өйдә социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган документларның ачык булуын тәэмин итү (устав (нигезләмә), кулланмалар, кагыйдәләр, социаль хезмәтләр күрсәтү технологияләре һәм методикалары, законнар нигезендә булырга тиешле башка документлар);

әлеге социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче социаль хезмәтләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрдән файдаланучылар саны;

социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләрне урнаштыру шартларыннан файдалана алу (шул исәптән тереклек эшчәнлегендә мөмкинлекләре чикләнгән булуын исәпкә алып, инвалидлар һәм башка затлар өчен социаль хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеге булу);

социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең штаты белгечләр белән комплектланган булу һәм аларның квалификациясе;

социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм кагыйдәләре, өйдә социаль хезмәт күрсәтүне оештыру турында мәгълүмат булу;

социаль хезмәтләр сыйфатын һәм аларны күрсәтү нәтиҗәлелеген күтәрү (социаль хезмәтләр күрсәткәндә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче эшчәнлеген камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралардан чыгып билгеләнә).

## V. Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге

5.1. Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле документлар:

5.1.1. Индивидуаль программа;

5.1.2. Социаль хезмәтләрдән файдаланучы (законлы вәкиле) шәхесен таныклый торган документ;

5.1.3. Законлы вәкил вәкаләтләрен раслый торган документ (ул мөрәҗәгать иткәндә);

5.1.4. Социаль хезмәтләрдән файдаланучының яшәү урынын һәм (яки) тору урынын, гамәлдә яшәү урынын раслый торган документ;

5.1.5. Социаль хезмәтләрдән файдаланучы белән яшәү урыны буенча бергә теркәлгән затлар турында мәгълүматларны үз эченә алган документ;

5.1.6. Граждан белән яшәү урыны буенча бергә яшәүче затларны аның гаилә әгъзаларына кертүнең хокукый нигезләрен раслый торган документ;

5.1.7. Социаль хезмәтләрне түләүсез күрсәтү өчен җан башына уртача керемне билгеләү өчен кирәкле социаль хезмәтләрдән файдаланучының һәм аның гаилә әгъзаларының (булганда) керемнәре, аның (аларның) мөлкәте турындагы документлар;

5.1.8. Гариза бирүчене әлеге Тәртипнең 3.5.1 – 3.5.3 нче пунктларында күрсәтелгән, җан башына уртача кереме күләменә бәйсез рәвештә социаль

хезмәтләрдән түләүсез файдаланырга хокуклы гражданнар категорияләренә керүен раслый торган документ.

5.2. Документлар төп нөсхәләрдә яки билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләрдә тапшырыла.

Социаль хезмәтләрдән файдаланучы тарафыннан тапшырылган документлар күчермәләрен, төп нөсхәләрен күрсәткәндә, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче мөстәкыйль рәвештә таныклый.

5.3. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле документлар социаль хезмәтләрдән файдаланучы тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә федераль һәм республика законнары таләпләре нигезендә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында бирелергә тиеш.

Гариза бирүче шәхсән бирергә тиешле документларга «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлештә күздә тотылган документлар керә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында бирелергә тиешле яки социаль хезмәтләрдән файдаланучы үз инициативасы буенча тапшыра торган документларга түбәндәгеләр керә:

пенсия күләмен раслый торган документ;

социаль хезмәтләрдән файдаланучы белән яшәү урыны буенча бергә теркәлгән затлар турында мәгълүматларны үз эченә алган документ.

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашкан очракта, әлеге документлар социаль хезмәтләрдән файдаланучыдан таләп ителми, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә ала.

## VI. Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр эшчәнлегенә карата башка таләпләр

6.1. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәткәндә социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны мәгълүмати тәэмин итүгә таләпләр:

6.1.1. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче өйдә социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнарга аларның хокуклары һәм бурычлары турында, социаль хезмәтләрнең төрләре, аларны күрсәтү вакытлары, тәртибе һәм шартлары хакында, әлеге хезмәтләргә тарифлар турында һәм социаль хезмәтләрдән файдаланучы өчен аларның кыйммәте яисә әлеге хезмәтләрдән түләүсез файдалану мөмкинлеге хакында ачык формада түләүсез мәгълүмат бирә.

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан мәгълүмат бирү электрон элемтә яки телефон элемтәсеннән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, үзенең рәсми сайтында, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче бинасының мәгълүмат стендларында, массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат чыгару юлы белән, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр биналарында гражданнарны шәхсән кабул итүдә консультация биреп, башка гомуми файдаланудагы ысуллар белән гамәлгә ашырыла.

Социаль хезмәтләр һәм аларны күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче турында мәгълүмат торышы «Кулланучылар хокукларын яклау

турында» 1992 ел, 7 февраль, 2300-1 нче Россия Федерациясе Законы таләпләренә туры килергә тиеш.

6.1.2. Гражданнар социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче эше, социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче белгече кабул итүне көтүнең максималь вакыты 15 минут тәшкил итә.

6.1.3. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче Федераль законның 13 статьясы нигезендә үз эшчәнлеге турында мәгълүмат булган гомуми файдаланудагы мәгълүмат ресурсын формалаштыра, аны үз бинасындагы мәгълүмат стендларында, массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шул исәптән үз сайтында чыгарып, әлеге ресурстан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итә.

Социаль хезмәтләрдән файдаланучылар (аларның законлы вәкилләре) социаль хезмәтләр турында дөреслеккә туры килмәгән, үз вакытында булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат тапшырганга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

6.2. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчене матди-техник тәэмин итүгә һәм өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү куркынычсызлыгына таләпләр:

6.2.1. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче юридик зат буларак яисә индивидуаль эшмәкәр буларак теркәлгән булырга һәм аның законнар нигезендә лицензияләнергә тиешле эшчәнлек төрләренә лицензияләре, рөхсәтнамәләре, социаль хезмәтләр күрсәтүне җайга сала торган документлары, социаль хезмәтләр күрсәтү буенча кулланмалары, кагыйдәләре, технологияләр һәм методикалары, законнар нигезендә булырга тиешле башка документлары булырга тиеш.

6.2.2. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче документларның актуальлеген, аларны үз вакытында яңартуны һәм искергән документларны әйләнештән алуны даими тикшерүдә тотарга тиеш.

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәткәндә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы раслаган документларның бертип формаларын кулланырга тиеш, законнар нигезендә федераль дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган документлар формаларыннан тыш.

6.2.3. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүдән һәркемнең файдалана алуын тәэмин итә.

6.2.4. Социаль хезмәтләрдән файдаланучылар (аларның законлы вәкилләре) социаль хезмәтләр күрсәтүче оешма белгеченә мәгълүм булган шәхси характердагы мәгълүматның конфиденциальлегенә хокуклы.

Социаль хезмәтләрдән файдаланучылар (аларның законлы вәкилләре) шәхси характердагы мәгълүматны таратканга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

6.2.5. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче аны гамәлгә кую документларында билгеләнгән функцияләрне башкару, социаль хезмәтләрдән

файдаланучыларның хокукларын һәм ирекләрен яклау, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары белгечләренең хокукларын һәм ирекләрен саклау өчен федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә җавап тота.

6.3. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәткәндә кадрлар белән тәэмин итү дәрәҗәсенә карата таләпләр:

6.3.1. Социаль хезмәт белән тәэмин итүченең социаль хезмәтләрне сыйфатлы итеп күрсәтү өчен кирәкле һөнәри эшчәнлек төрләре буенча персоналы булырга тиеш.

Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәткәндә бер социаль хезмәткәр тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган социаль хезмәттән файдаланучыларның тәкъдим ителгән саны нормативы шәһәр җирендә – 10 кеше, авыл җирендә – 6 кеше, бер медицина хезмәткәре хезмәт күрсәтә торган файдаланучылар саны шәһәр һәм авыл җирендә 12 кеше тәшкил итә.

6.3.2. Тиешле квалификация белән берләттән, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче хезмәткәрләре социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның үзләренә карата ихтирамлы һәм кешелекле мөнәсәбәткә хокукларын сакларга тиеш.

6.3.3. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче хезмәткәрләре социаль хезмәтләр күрсәткәндә гамәлгә кую документларында каралган таләпләрне, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен үтәргә, аларның вазыйфаларын, хокукларын һәм җаваплылыгын билгели торган вазыйфаи инструкцияләр нигезендә үзләренә йөкләнгән функциональ вазыйфаларны сыйфатлы итеп башкарырга, һөнәри этиканы төгәл үтәргә тиеш.

6.4. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатына таләпләр:

6.4.1. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре һәм аларны социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләрнең күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләү һәрбер социаль хезмәтләрдән файдаланучыга карата социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

6.4.2. Социаль-көнкүреш хезмәтләрен күрсәтү сыйфатын бәяләү үз эченә түбәндәгеләрне бәяләүне ала:

өйгә азык-төлек продуктлары, беренчел кирәк-ярак сәнәгать товарлары, санитария һәм гигиена чаралары, үз-үзеңне карау чаралары, китаплар, газеталар, журналлар сатып алуда һәм китертүдә, ягулык сатып алуда, торак-коммуналь хезмәтләр һәм элемтә хезмәтләре өчен түләүдә булышлык күрсәтү, һәм ул социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның үз вакытында кирәкле азык-төлек һәм сәнәгать товарлары сатып алуга, шулай ук коммуналь-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү, элемтә өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүдә ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиеш;

ашарга пешерүдә, ашау (ашату) вакытында, су белән тәэмин итүдә, торак урыннарны җыештыруда, почта аша хәбәрләшүдә, торак урыннарга ремонт үткәрүдә ярдәм күрсәтүне оештыруда булышлык күрсәтү, һәм ул, социаль хезмәтләрдән файдаланучылар өчен нормаль тормыш шартларын булдыру максатларында, аларның әлеге мәсьәләләрне хәл итүдә мохтаҗлыкларын һәм ихтыяҗларын канәгатьләндерүне тәэмин итәргә тиеш;

сәламәтлекләре торышы аркасында үз-үзләрен мөстәкыйль рәвештә карый алмаган затларга гигиена хезмәтләре күрсәтү, һәм бу хезмәтләр социаль хезмәтләрдән файдаланучылар өчен кирәкле процедураларны аларның сәламәтлекләренә бернинди зыян, физик яки рухи газаплар һәм кыенлыклар китермичә үткәрүне тәэмин итәргә тиеш.

6.4.3. Социаль-медицина хезмәтләрен күрсәтү сыйфатын бәяләү үз эченә түбәндәгеләрне бәяләүне ала:

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның сәламәтлеген саклауга бәйле процедураларны үз вакытында һәм тулы күләмдә үткәрү;

сәламәтлекләре торышында тайпылышларны билгеләү өчен социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны күзәтүне үткәрү;

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның сәламәтлеген саклауга бәйле процедуралар, савыктыру чаралары үткәрү, һәм алар мөмкин кадәр ипләп һәм саклык белән, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга бернинди зыян китермичә гамәлгә ашырылырга тиеш;

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга социаль-медицина мәсьәләләре буенча консультация бирү чаралары, һәм алар, сәламәтлекне саклауга бәйле булган билгеле проблемаларны дөрес аңлап һәм хәл итеп, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга квалификацияле ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә тиеш;

адаптив физик культура буенча шөгыльләнүдә ярдәм күрсәтү, һәм ул, сәламәтлекне ныгыту өчен системалы рәвештә эшләү максатларында, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның сәламәтлеге өчен уңайлы һәм куркынычсыз физик күнегүләр комплексы хезмәтләрен үзләштерүен тәэмин итәргә тиеш.

6.4.4. Социаль-хокукый хезмәтләр сыйфатын бәяләү үз эченә түбәндәгеләрне бәяләүне ала:

документларны рәсмиләштерүдә һәм торгызуда ярдәм күрсәтү, һәм ул социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга билгеләнешенә бәйле рәвештә кирәкле документларның эчтәлеген аңлатуны, документлар текстын бәян итү һәм язуны (кирәк булганда) яки форма бланкларын тутыруны, теркәп җибәрелә торган хатлар язуны тәэмин итәргә тиеш;

социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга юридик ярдәм күрсәтү нәтиҗәлелеге, һәм ул социаль хезмәтләрдән файдаланучылар алдындагы хокукый проблемаларны үз вакытында һәм объектив хәл итүне тәэмин итәргә тиеш.

6.4.5. Социаль-педагогик хезмәтләр сыйфатын бәяләү үз эченә өйдә тәрбияләнә торган инвалид балаларның ата-аналарына һәм законлы вәкилләренә мондый балаларны аларның шәхесен үстерүгә юнәлдерелгән, үз-үзләренә хезмәт күрсәтү, аралашу һәм тикшерүдә тоту күнекмәләренә өйрәтү буенча ярдәм оештыруны бәяләүне ала.

---

Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә кушымта

## Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемнәре һәм стандартлары

| Т/с | Социаль хезмәт исеме | Социаль хезмәт тасвирламасы | Социаль хезмәт күләме | | Социаль хезмәт күрсәтү вакытлары | Социаль хезмәт күрсәтүне финанслауның җан башына нормативы | Социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре һәм нәтиҗәлелеген бәяләү* | Социаль хезмәт күрсәтү шартлары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | үлчәү берәмлеге | хезмәт күрсәтү ешлыгы | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Социаль-көнкүреш хезмәтләре | | | | | | | | |
| 1. | Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләрдән файдаланучы акчасы исәбеннән түбәндәгеләрне сатып алу һәм китерү**: | Сатып алу социаль хезмәтләрдән файдаланучы яши торган районда урнашкан сәүдә оешмаларында гамәлгә ашырыла. Хезмәт клиенттан товар сатып алуга, заказ бирелгән товар сатып алуга, сатып алынган товарларны өйгә (госпитальләштерү чорында медицина оешмасына) китертүгә акча алуны һәм кас- | | | индивидуаль программада билгеләнгән вакытларда | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, | хезмәтләрне тулы күләмдә, үз вакытында, нәтиҗәле күрсәтү, шикаятьләр булмау | Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль |

*Тәртипнең 6.4 нче пункты нигезендә.
**Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1993 ел, 6 февраль, 105 нче карарында билгеләнгән иң чик рөхсәт ителгән йөкләнешләр нормаларын исәпкә алып (башка эш белән чиратлаштырып авыр йөкләр күтәрү һәм күчерү (сәгатенә 2 тапкырга кадәр) – 10 кг, эш сменасы вакытында даими авыр йөкләр күтәрү һәм күчерү – 7 кг).

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1. | азык-төлек продуктлары | са чегы буенча тулысынча исәп-хисап ясауны үз эченә ала. Санкцияләнмәгән сәүдә урыннарында товарлар сатып алу тыела. Сатып алына торган товарлар билгеләнгән яраклылык вакытына туры килергә тиеш | сатып алу | айга 1 – 8 тапкыр | | социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә ел саен исәпләнә | | хезмәтләр күрсәтү тәртибенең (алга таба – Тәртип) 4.4 нче пункты нигезендә |
| 1.2. | беренчел кирәк-ярак сәнәгать товарлары, санитария һәм гигиена чаралары, үз-үзеңне карау чаралары | | сатып алу | айга 1 – 2 тапкыр | | | | |
| 1.3. | дарулар | Дарулар һәм медицина әйберләре сатып алу үз эченә рецепт язып бирүне ала, шул исәптән ташламалы (кирәк булганда) | сатып алу | айга 1 – 3 тапкыр | | | | |
| 1.4. | медицина әйберләре | | сатып алу | айга 1 тапкыр | | | | |
| 1.5. | китаплар, газеталар, журналлар | Хезмәт кирәкле китаплар, газеталар, журналлар сатып алуны, китапханәдән китаплар китертүне һәм кире илтеп бирүне, шулай ук вакытлы басмага язылуны рәсмиләштерүне күздә тота | сатып алу | айга 1 тапкыр | | | | |
| 1.6. | мәдәни-ял итү чараларына билетлар | Хезмәт мәдәни-ял итү чараларына билетлар сатып алуны күздә тота | хезмәт күрсәтү | кварталга 1 тапкыр | | | | |
| 2. | Үзәктән ягып җылытылмый торган һәм (яки) су белән тәэмин ителми торган торак урыннарда | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | яшәүче социаль хезмәтләрдән файдаланучылар өчен: | | | | | | | |
| 2.1. | социаль хезмәтләрдән файдаланучы акчасы исәбеннән ягулык сатып алу ** | Хезмәт үз эченә ягулык сатып алуга заказ урнаштыруны (агымдагы елның 1 сентябренә кадәр) алган торак урынны ягып җылытуны оештыру чараларын күздә тота һәм клиенттан акча алудан, сатып алганга түләүдән, ягулыкны китерүне оештыруда булышлык күрсәтүдән, саклау өчен даими урынга урнаштырудан һәм клиент белән касса чегы буенча тулысынча исәп-хисап ясаудан тора | сатып алу | елга 1 – 2 тапкыр | | | | |
| 2.2. | мичкә ягу ** | Хезмәт торак урында һәм мунчада мичкә ягуны күздә тота, бер тапкыр ягарга кирәкле ягулыкны китертүне, әледән-әле мичне көлдән чистартуны үз эченә ала | ягып җылыту | айга 1 – 8 тапкыр | | | | |
| 2.3. | су белән тәэмин итү** | Хезмәт иң якында булган су белән тәэмин итү чыганагыннан 40 литр эчә торган су китертүне күздә тота | китертү | айга 1 – 8 тапкыр | | | | |
| | | Шәхси мунчасы булган социаль хезмәтләрдән файдаланучыга гигиена процедураларын үткәрү өчен | китертү | айга 1 – 2 тапкыр | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өстәмә рәвештә 50 литр су китертү тәэмин ителә | | | | | | |
| 3. | Социаль хезмәтләрдән файдаланучы акчасы исәбеннән торак-коммуналь хезмәтләр һәм элемтә хезмәтләре өчен түләү | Хезмәт исәпләү җайланмаларыннан күрсәткечләрне язып алуны, торак-коммуналь хезмәтләр, элемтә хезмәтләре, салым түләүләре өчен түләүгә квитанцияләр тутыруны, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр рәсмиләштерү документларын җыюны һәм әлеге документларны билгеләнгән урыннар буенча илтеп тапшыруны, акча алу һәм хезмәтләр өчен түләүне күздә тота | һәр түләү төре буенча түләү | айга 1 тапкыр | | | | |
| 4. | Социаль хезмәтләрдән файдаланучы акчасын түләп, әйберләрне юарга, химик юл белән чистартуга, ремонтка бирү һәм кире китертү ** | Хезмәт клиенттан акча алу, әйберләрне көнкүреш хезмәтләре күрсәтү оешмаларына илтү, башкарылган заказны өйгә китертү һәм клиент белән касса чегы буенча тулысынча исәп-хисап ясауны күздә тота | хезмәт күрсәтү | айга 1 – 2 тапкыр | | | | |
| 5. | Социаль хезмәтләрдән файдаланучы акчасы | Хезмәт почта бүлеге аша посылка яки телеграмма, заказлы хат, почта тартмасы аша хат җибәрүне күздә то- | җибәрү | айга 1 тапкыр | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | исәбеннән почта аша хәбәрләшү ** | та. Хезмәт үз эченә хатлар язу һәм укуны ала | | | | | | |
| 6. | Торак урыннарны җыештыру: | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | | | | | | |
| 6.1. | торак булмәдә идән юу** | 33 кв.метр мәйданлы идәнне себерү һәм (яки) юу; | җыештыру | айга 1 – 2 тапкыр | | | | |
| 6.2. | чүп чыгару** | көнкүреш калдыкларын чыгару (1 чиләк) | чүп чыгару | айга 1 – 12 тапкыр | | | | |
| 6.3. | сыек көнкүреш калдыкларын чыгару** | Канализация системасы булмаган торак урында яшәүче социаль хезмәтләрдән файдаланучыга сыек көнкүреш калдыкларын чыгару буенча (1 чиләк) өстәмә рәвештә хезмәт күрсәтелә | көнкүреш калдыкларын чыгару | айга 1 – 12 тапкыр | | | | |
| 6.4. | торак урынга керә алуны тәэмин итү өчен йорт яны территориясен кардан чистарту ** | Хосусый торак секторында яшәүче социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга 10 кв.метр мәйданлы торак урынга керә алуны тәэмин итү өчен йорт яны территориясен кардан чистарту күздә тотыла (ноябрьдән мартка кадәрге чорда) | кар көрәү | айга 1 – 8 тапкыр | | | | |
| 7. | Әзерләүдә һәм (яки) ашарга пешерүдә ярдәм күрсәтү | Хезмәт күрсәтү азык-төлек продуктларын пешерергә әзерләүне (юу, чистарту, турау) күздә тота | продуктларны әзерләү | айга 1 – 8 тапкыр | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәламәтлекләре торышы аркасында үзләре ашарга пешерә алмаган социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга бер ризык пешерү тәэмин ителә | ашарга пешерү | айга 1 – 12 тапкыр | | | | |
| 8. | Ашарга (ашатуда) ярдәм итү | Хезмәт ашаганда (ашатканда) ярдәм күрсәтүне күздә тота. Хезмәт сәламәтлек торышы аркасында үзләре ашый алмаган социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга күрсәтелә | ашарга ярдәм итү | айга 1 – 12 тапкыр | | | | |
| 9. | Гигиена хезмәтләре күрсәтү: | Хезмәт сәламәтлекләре торышы аркасында үзләре мөстәкыйль рәвештә булдыра алмаган затларга гигиена хезмәтләре күрсәтүне күздә тота | | | | | | |
| 9.1. | душта, мунчада яки ваннада юу | | хезмәт күрсәтү | айга 1 – 2 тапкыр | | | | |
| 9.2. | юындыру | | хезмәт күрсәтү | айга 1 – 12 тапкыр | | | | |
| 9.3. | чәч тарау | | хезмәт күрсәтү | айга 1 – 12 тапкыр | | | | |
| 9.4 | урын-җирләрне алыштыру | | хезмәт күрсәтү | айга 1 – 4 тапкыр | | | | |
| 9.5. | тырнак кисү (кулларныкын, аякларныкын) | | хезмәт күрсәтү | айга 1 – 2 тапкыр | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Социаль-медицина хезмәтләре | | | | | | | | |
| 10. | Сәламәтлек хәлендә тайпылышларны билгеләү максатларында, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның сәламәтлек торышын системалы рәвештә күзәтү, шул исәптән сәламәтлек торышын күзәтүгә бәйле процедуралар үткәрү: | Хезмәт, социаль хезмәтләрдән файдаланучы зарланганда, социаль хезмәтләрдән файдаланучы җиһазларыннан файдаланып, сәламәтлек торышын күзәтүгә бәйле процедуралар үткәрүне күздә тота | | | индивидуаль программада билгеләнгән вакытларда | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә ел | хезмәтләрне тулы күләмдә, үз вакытында, нәтиҗәле күрсәтү, шикаятьләр булмау | Тәртипнең 4.4 нче пункты нигезендә |
| 10.1. | тән температурасын үлчәү | | үлчәү | айга 1 – 12 тапкыр | | | | |
| 10.2. | кан басымын үлчәү | | үлчәү | айга 1 – 12 тапкыр | | | | |
| 10.3. | йогышлы авырулар, чиләнеп тишелгән урыннар булу-булмауга тире капламнарына визуаль кон- | | контроль | айга 1 – 12 тапкыр | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | троль | | | | | саен исәпләнә | | |
| 11. | Медицина процедураларын үткәрү: | Хезмәт табиб билгеләве буенча, социаль хезмәтләрдән файдаланучының дарулары һәм медицина әйберләреннән файдаланып, медицина процедуралары үткәрүне күздә тота | | | | | | |
| 11.1. | күзгә дару салу, майлау, горчичниклар, компресслар кую | | һәр төр буенча курс | кварталга 1 тапкыр | | | | |
| 11.2. | даруларны мускулга һәм (яки) тирегә кадау | | һәр төр буенча курс | кварталга 1 тапкыр | | | | |
| 11.3. | яралы урыннарны эшкәртү һәм бәйләү | | курс | кварталга 1 тапкыр | | | | |
| 12. | Савыктыру чаралары үткәрү | Хезмәт табиб киңәшләре буенча хәлдән килгәнчә физик күнегүләр эшләүдә, савыктыру чаралары үткәрүдә ярдәм күрсәтүне күздә тота | чара | айга 1 – 10 тапкыр | | | | |
| 13. | Социаль-медицина мәсьәләләре буенча консультация бирү | Хезмәт социаль хезмәтләрдән файдаланучыга сәламәт яшәү рәвешен алып бару, яшькә һәм сәламәтлек хәленә ярашлы рәвештә рациональ туклану, савыктыру чаралары үткәрү мәсьәләләре буенча консультация бирүне күздә тота | консультация бирү | айга 1 тапкыр | | | | |
| Социаль-хокукый хезмәтләр | | | | | | | | |
| 14. | Социаль хезмәтләрдән фай- | Хезмәт социаль хезмәтләрдән файдаланучыга шәхесне таныклый торган документ- | кирәк булан | елга 1 тапкыр | индивидуаль про- | Татарстан Республикасы | хезмәтләрне тулы күләмдә, үз | Тәртипнең 4.4 нче пункты |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | даланучының документларын рәсмиләштерү һәм торгызуда ярдәм күрсәтү | лар, башка шәхси документлар, шул исәптән социаль ярдәм чаралары, пенсияләр, пособиеләр, техник тернәкләндерү чаралары, шифаханә-курорт дәвалавы, тернәкләндерү һ.б. алу өчен кирәкле документлар алуда ярдәм күрсәтүне, шулай ук югалткан (яраксызга әйләнгән) документларны торгызу өчен кирәкле гамәлләр башкаруны күздә тота.<br>Хезмәт (документларны рәсмиләштергәндә түләргә кирәк булганда) социаль хезмәтләрдән файдаланучы акчасы исәбеннән күрсәтелә.<br>Хезмәт индивидуаль программаны хәлләр үзгәрүгә яки гамәлдә булу вакыты чыгуга бәйле рәвештә яңадан рәсмиләштерүдә булышлык күрсәтүне күздә тота | очракта һәр документ буенча хезмәт күрсәтү | | граммада билгеләнгән вакытларда | Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә ел саен исәпләнә | вакытында, нәтиҗәле күрсәтү, шикаятьләр булмау | нигезендә |
| 15. | Юридик хезмәтләрдән файдалануда ярдәм күрсәтү | Хезмәт түләүсез юридик ярдәм алуда булышлык күрсәтүне күздә тота (хокук булганда) | хезмәт күрсәтү | елга 1 тапкыр | | | | |
| Социаль-педагогик хезмәтләр | | | | | | | | |
| 16. | Өйдә тәрбияләнә торган инвалид бала- | Хезмәт үз эченә түбәндәгеләрне ала:<br>өйдә тәрбияләнә торган ин- | өйдә 1,5 сәгатькә | елга 9 тапкыр | индивидуаль про- | Татарстан Республикасы Министрлар | хезмәтләрне тулы күләмдә, үз | Тәртипнең 4.4 нче пункты |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ларның ата-аналарына яки законлы вәкилләренә мондый балаларны аларның шәхесен үстерүгә юнәлдерелгән, үз-үзләренә хезмәт күрсәтү, аралашу һәм тикшерүдә тоту күнекмәләренә өйрәтү буенча ярдәм оештыру | валид балаларның ата-аналарын һәм законлы вәкилләрен мондый бала белән аның онытылган яисә формалаштырылмаган социаль күнекмәләрен (үз-үзләренә хезмәт күрсәтү, аралашу һәм тикшерүдә тоту) формалаштыру, социаль кабул ителгән кыйммәти ориентирларны һәм үз-үзеңне тоту нормаларын булдыру буенча мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнергә өйрәтү максаты белән аларның өенә бару; | кадәр индивидуаль дәрес | | граммада билгеләнгән вакытларда | Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә ел саен исәпләнә | вакытында, нәтиҗәле күрсәтү, шикаятьләр булмау | нигезендә |
| | | алган белемнәрне куллану мәсьәләләре буенча консультация бирү (телефон элемтәсе, «Интенет» мәгълумат-телекоммуникация челтәре аша) | читтән торып 30 минутка кадәр консультация бирү | | | | | |